Февраль • 2021 ел • № 2 (38)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

## Көмеш кыңгырау чыңлады

Быел «Көмеш кыңгырау» үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп узды. Туган тел көне уңаеннан безнең гимназия укучылары мәртәбәле кунаклар – әлеге газета хезмәткәрләре белән очрашу бәхетенә ирештеләр. Әлбәттә, бу бәхетле очрак, чөнки газета яшүсмерләр өчен чыга, ул газета битләрендә безнең гимназия укучыларының күпме уңышлары, иҗатлары яктыртылды һәм яктыртыла, тагын әле ул газета хезмәткәрләре танылган әдипләр, оста журналистлар да ич! Сүз уңаеннан килгән кунаклар кемнәр иде соң диярсез? «Көмеш кыңгырау» газетасын оештырган, күп еллар аның баш мөхәррире вазыйфасын башкарган яраткан әдибебез Факил абый Сафин, газетаның баш мөхәррире – Ризида апа Гасыймова, танылган шагыйрә, газетаның хезмәткәре – Лилия апа Фаттахова.

Әлеге очрашу безнең өчен бик файдалы булды: без Ризида апа Гасыймова белән Лилия апа Фаттахова уздырган мастер-класста катнашып, каләм тибрәтеп, журналист һөнәренең үзенчәлекләре хакында сөйләштек.

Аннан очрашу Мәҗлесләр залында гимназиянең 5–8 сыйныф укучылары катнашында дәвам итте. Кичә шигырен дә, көен дә Факил абый Сафин иҗат иткән «Икенче гимназиям» җыры белән башланып китте. Укучылар, Факил абыйга дәррәү кул чабып, үзләренең рәхмәтләрен белдерделәр. Алга таба Р.Харисның «Кеше кайчан матур була?» шигырен Айсылу Ишалина яңгыратты. Хактан да, күнелләре – хезмәтләре белән матур кешеләр – журналистлар башкарган хезмәт кешене зурлый, матур итә. Әйдәгез, газетаның тарихына бераз тукталып китик.

«Көмеш кыңгырау» – республикакүләм балалар-яшүсмерләр газетасы. Сигез битле булып атнага бер чыга торган матур, кызыклы басма ул. Аның беренче номеры 1996 елның 3нче гыйнварында дөнья күргән. Аңа кадәр ике ел дәвамында газета «Шәһри Чаллы»ның кушымтасы буларак чыгып килгән. Беренче редакторы – танылган журналист Нәсимә апа Садыйкова.

2010 елдан 9 ел дәвамында газета белән күренекле әдип Факил абый Сафин җитәкчелек итте. 2019 елдан баш мөхәррир вазыйфаларын Ризидә Гасыймова башкара.

«Көмеш кыңгырау» «Бәллүр каләм» журналистика бәйгесендә 3 тапкыр (2000, 2006, 2013 елларда), «Многоликая Россия», «Бумеранг», «Кеше һәм табигать», «Доверие и безопасность» кебек бәйгеләрдә күп мәртәбәләр җиңү яулаган газета». Интернет челтәрендә әнә шундый мәгълүмат табып укырга мөмкин. Баксаң, газетаны оештыру эшләре 1993 елдан ук башланган икән! Бу турыда газетаның башлангычында торган Факил абый Сафин үзенә генә хас җор тел белән бик үтемле итеп сөйләде. «Көмеш, чөнки ул



(Ахыры. Башы беренче биттә.)

саф, тыйнак, кыңгырау, чөнки ул уяу булырга чакырып тора», – дип газетага үзе куйган исемнең мәгънәсен аңлатты ул.

Гимназия укучылары Факил абый безгә кайчан гына килсә дә, үзен һич игътибарсыз калдырмыйлар. Бу юлы да Гыйниятуллина Ильфира Сабировна җитәкләгән 3в сыйныф укучылары: Гайнетдинов Ислам «Бәхет нәрсә ул?», Сибгатова Заринә «Кояшлы балалар», Кашапова Зилия «Карбыз», Фәтхетдинова Ясминә «Ишек», Нуретдинова Азалия «Әнием» шигырьләрен бик матур итеп сөйләделәр.

Шигърият дулкыннары иплән кенә Лилия апа Фаттахова иҗатына барып тоташты. Лилия апаның да балалар өчен иҗат иткән шигырьләрен 3в сыйныф укучылары Гафиятова Луиза («Аюның теше сызлый»), Габидуллина Камилә («Аю-болыт»), Ризванов Данияр («Болытта»), Әүхәдиева Әдилә («Карга белән Сара») тырышып сөйләделәр.

Шагыйрәнең мәсәлләреннән торган гөлләмә – кичәнең матур бизәге булды. 8в сыйныф кызлары мәсәлләрне бик сәнгатьле итеп сөйләделәр, ә кичәне алып баручы Нурисламова Энҗе Әзһәмовна һәр мәсәлнең эчтәлеген шәрехләп барды. Аминова Азалия «Көтү хәлләре», Ишалина Айсылу «Тигезлек», Билалова Алинә «Кайсы яхшырак?» Валиева Мәликә «Алдавыч сөенеч», Ризатдинова Мәрьям «Соңарган үкенеч», Госманова Динара «Һәр теләкнең ахыры хәерле түгел», Нурисламова Алия «Хакыйкать», Шәмсетдинова Азалия «Хакыйкать хакында», Габдрахманова Алия «Уяулык кемгә кирәк?» мәсәлләрен бик оста итеп яттан сөйләделәр.

Әлеге мәсәлләрдә җәмгыятьтәге проблемаларның: таркаулыкның, битарафлыкның, мин-минлекнең фаш ителүе укучыларны уйландырды. Шул җәһәттән Ризидә апа Гасыймованың «Татарларның кайберләре ни өчен татар телендә аралашырга теләмиләр?» соравына җаваплар тыңланды. Шулай итеп, үзебез дә сизмәстән, бик әһәмиятле сорауны күтәрдек.

Әлеге очрашу күңелләрдә бик матур тойгылар уятты, «Көмеш кыңгырау» газетасы хезмәткәрләренә хөрмәтебез артты, әлеге газетаның безнең өчен иҗат мәйданы икәненә тагын бер кат инандык.

**Алия НУРИСЛАМОВА**

# Бар дөнья – театр...

Мәхәббәт – караңгылыкта һәм томанда юкка чыкмый торган, давыл өстендә күтәрелгән маяк…

«Бар дөнья – театр, ә без барыбыз да анда актерлар», – дип Шекспир юкка гына әйтмәгәндер. Театрдан башка торып буламы? Юк. Шуңа да һәрвакыт сәхнәдә тамаша күрсәтелергә тиеш. Без нәкъ шулай эшлибез дә.

Спектакль «Король театры труппасы» дип атала. Әмир Хаертинов: «Миңа ошый, бик пафослы», – диде.

Шекспирның мәхәббәт хакында язган әсәрләре мине һәрвакыт әсир итә, чөнки ул мәхәббәт хисен серле итеп тасвирлый белә.

чөнки һәр кешенең үз теләге, фикере исәпкә алынып эшләнә.

Бу юлы мине бер нәрсә шаккаттырды: спектакльдә уйнарга тәкъдим иткән укучыларның баш тартуы! Ничек инде шундый мөмкинлектән баш тартырга була? Шуңа күрә спектакльдә катнашучы укучыларның күбесе «уйный алмасак, безгә үпкә тотмагыз» дип килделәр. Зарипов Артур белән Якупов Булатның безнең проектка килүе, аларның тырышулары минем икеләнүләремне сызып ташлады.

Эшнең каралама өлеше ул «нонстоп». Ике ай дәвамында көнгә ике тапкыр репетиция ясау, тәнәфесләр

Бу минем сәхнәгә куйган унөченче спектаклем. Аны сәхнәгә кую фикере миндә узган ел туды. Гадәттә, мин укучыларга карыйм да аларда үзем укыган әсәр геройларына хас сыйфатларны эзли башлыйм. Аннан мин спектакль турында уйлыйм. Алынган текстны минимумга кадәр кыскартам, эш барышында азагын уйлап бетерәм. Мин һәр идеяны кабул итәм, хәтта иң кыргый булып күренгәнен дә. Нәтиҗә бер үк вакытта төп фикердән бай да ярлырак та булып тоела. Ярлырак, чөнки нәтиҗә минем башымда яралган фикердән үзгә килеп чыга, байрак, вакытында да әлеге эш белән кайнау… Мин укучыларыма рәхмәттән тыш нәрсә әйтә алам? Моны һәркем булдыра алмый. Былтыр куйган «Хезмәтче куян» спектаклендә уйнаган укучыларым да шундый иде. Текстны ятлау, сәхнәдә уйнау – искиткеч күп көч һәм сабырлык сорый торган хезмәт. Рәхмәт ата-аналарга, аларның көче белән сәхнә костюмнары тегелде. Спектакль уңышлы чыккач, күңел яңадан канатлана башлый. Рәхмәт укучыларыма һәм галиҗәнап тамашачыма!

**Алсу Икрамовна ГАЛИЕВА**






# «Милли мультfest» балалар кинофестивале

Быел беренче тапкыр Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе инициативасы белән «Татарстан Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» җәмгыяте катнашында «Милли мультfest» республика балалар кинофестивале гамәлгә куелды.

Мәнә без дә, 5б сыйныфы укучылары, җиң сызганып, әлеге фестивальдә катнашырга булдык һәм 2 номинацияне сайладык:

1. Татар телендә анимацион фильмнар
2. Балалар өчен татар телендә кыска метражлы фильмнар.

Беренче номинация буенча Булатова Диләрә үзе язган «Ай белән Кояш» әкиятенә мультфильм төшерергә алынды. Башта әкиятне сценарийга әйләндереп чыктык. Аннан соң кәгазьдән персонажларны ясап, аларны бамбук таякчыкларга беркетеп, хәрәкәтләндерергә өйрәндек. Диләрә тавыш режиссеры да, сценарий авторы да, төшерүче рольләрен дә тулаем башкарып чыкты. Аның эше шәһәрдә 3нче урынга лаек булды.

Иң кызыклысы һәм мавыктыргычы «Татарча Ералаш» төшерү булды. Таләпләр буенча, ул кыска метражлы, ягъни 5-6 минуттан артмаска, балаларның саф татарча сөйләмен күрсәтергә һәм it-технологияләрне уңышлы куллануда гыйбарәт иде. Беренче эш итеп, әлбәттә, без интернет челтәреннән русча Ералашларны, сугыш турындагы кыска метражлы фильмнарны карап чыктык. Ләкин төшерер өчен үзебезнең мөмкинлекләргә туры килерлеген, күп чыгымнар таләп итмәгәнен, балаларның холык, яшь үзенчәлекләренә туры килерлеген үземә язарга туры килде. Адилә күтәреп килгән алтын балыкны кызларның төрле теләкләрен үтәп утыруын күзәткән сыйныф җитәкчесе, укыту сыйфатын күтәрү максатыннан балыкны үзенә ала. Алтын балык ярдәме белән сыйныфның иң йомшак, шук малае Ясәбиев тә, Хәбибуллин да «5»ле алып кереләр. Бу могҗизаны күргән сыйныф җитәкчесе алга таба да алтын балыкны үзенең бетмәс-төкәнмәс эшләренә ярдәм итүен теләп кала. Әлбәттә, фильмны төшергәнче рольләрне ятлап карарга, бернич тапкыр кабатларга туры килде. Ә инде монтажларга әниләр ярдәме кирәк булды, безгә Гүзәл Дамировна булышты. Шулай итеп «Татарча Ералаш» шәһәрдә 1нче дәрәҗә Дипломга лаек булды.

13нче февраль көнне Зәй шәһәрендә фестивалнең беренче зона туры үтте. Әлеге турга 12 район вәкилләре җыелган иде: Мамадыш, Бөгелмә, Алабуга, Менделеевск, Әгерже, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Аксубай, Норлат, Лениногорск, Әлмәт, Чирмешән, Яр Чаллы.

Жюри составына:Татарстан Республикасының халык артисты, ТР Дәүләт советы депутаты, Дәүләт советында телләрне саклау һәм үстерү комиссия әгъзасы, республика-күләм балалар кинофестивале жюри әгъзасы Рамил Төхвәтуллин; ООО «Татармультфильм»ның баш режиссеры Сергей Киатров; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ГБУК РТ «Татаркино»ның директоры Миләүшә Айтуганова иде.

Әлеге зона турына тәкъдим 300 эш арасыннан 150 эш сайлап алынган иде. Бу бәйгегә килгән җитәкчеләр, укытучылар көн дәвамында шушы 150 фильмны жюри белән бергә карап, кимчелекләрен шунда ук аңлап карый алдылар. Әлбәттә, бу бик дәвамлы, зур сабырлык, көч таләп итә торган ачык бәйге булды. Без әлеге турда шулай ук зона этабын җиңеп республика турына үттек. Шатлык, сөенечнең чиге булмады!

Фестивальнең финалы 23нче апрельдә, Татарстанда Туган телләр көне унаеннан Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт Филармониясендә үткәреләчәк.

**Суфия Василовна ВАЛЕЕВА**



# Муса Җәлилгә 115 яшь

*2021 елның 15нче февралендә бөек шагыйрь, каһарман Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулды. Безнең гимназиядә Җәлилнең шигырьләре инглиз, рус, татар телләрендә яңгырады. Сез шагыйрьнең тормышы, иҗаты белән танышмы? Үзегезне тикшереп карагыз.*



*1. М.Җәлил кайда туган?* (Хәзерге Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында Мостафа абзый гаиләсендә дөньяга килә).

*2. М.Җәлилнең беренче шигырьләре кайчан басылып чыга?* (1919 нчы елда Оренбургтагы фронт гәзитләрендә «Бәхет», «Ирек бәйрәмендә» исемле беренче шигырьләре басылып чыга).

*3. М.Җәлил кайда укып югары белем ала?* (Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать бүлегендә (1927–1931)).

*4. 1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театры ачыла. М.Җәлил анда нинди вазыйфа башкара?* (Ул әдәби бүлек мөдире була. Беренче татар опералары өчен либреттолар иҗат итүне оештыра).

*5. М.Җәлил кайчан сугышка китә?* (1941 елда. Хәрби-сәяси курсны тәмамлаганнан соң, Җәлил өлкән политрук исеме ала һәм Волхов фронтына җибәрелә. «Отвага» газетасында эшли).

*6. М.Җәлил кайчан әсирлеккә төшә?* (1942 елда. Җәйдә Волхов фронтында барган каты сугышлар вакытында ул каты яраланып, дошман кулына төшә, лагерьга озатыла).

*7. М.Җәлилнен тормышы кайчан, ничек өзелә?* (1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилне һәм аның белән 11 көрәштәшен үлем җәзасына хөкем итәләр).

*8. Муса Җәлил исемен йөрткән кече планета бар дип уйлыйсызмы?* (Бар икән! 3092 нче әлеге планета – «Җәлил» астероиды – Кырымдагы астрофизик обсерваториядә астроном Т.Смирнов тарафыннан 1972 елда ачыла. Аның Кояштан ераклыгы – 2,4–2,8 астрономик берәмлек. Кояш тирәли 4,1 ел эчендә әйләнеп чыга).

*9. Татарстанда Җәлил исемен мәңгеләштергән нинди истәлекле урыннар бар?* (Казанда Муса Җәлил музей-фатиры; Муса Җәлил урамы; 1нче Май мәйданында Муса Җәлилгә һәм җәлилчеләргә һәйкәл; Балтач районының Карадуган авылында Муса Җәлил музее; Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры; Сарман районында Җәлил бистәсе; Әтнә, Апас, Тукай, Сарман, Минзәлә районнарында шагыйрь исемен йөрткән хуҗалыклар).

*10. Казан Кремле алдындагы Муса Җәлил һәйкәлен күпләрегез күргәндер. Аны иҗат иткән сынчы кем? Ул кайчан куелган?* (Атаклы сынчы, скульптор В.Е.Цигаль белән архитектор Л.Голубовский иҗат иткән. 1966 елда Казан Кремле алдында мәһабәт һәйкәл куелган).

*11. «Моабит дәфтәрләре» тарихын беләсезме? Ул ничә дәфтәрдән тора? Илгә кайчан кайтып җитә?* («Моабит дәфтәрләре» – шартлы исем. Аны шагыйрь үзе куймый, шигырьләрне, Моабит төрмәсендә теркәлүенә, төрмәдә иҗат ителүенә карап, Туган илдә шулай атап йөртә башлыйлар.

Ул дәфтәрләрнең беренчесе Казанга 1946 елда кайтып төшә. 1944 елда төрмәдән чыккан беренче дәфтәрне Габбас Шәрипов Франциягә алып килә, Ле-пюи лагерендагы татар әдипләре аны, каршылык хәрәкәтендә катнашкан француз партизанкасы Мария Дубизада саклап, сугыш тәмамлангач, Нигъмәт Терегулов аша илгә кайтара. Беренче дәфтәр – гарәп хәрефләре белән язылган. Нигъмәт Терегулов дәфтәрдәге бөтен текстны әйбәтләп күчереп чыга. Шушы дәфтәрнең бер битендә ватанпәрвәр шагыйрьнең васыяте язылган. Дәфтәрләрнең икенчесен, латин хәрефләре белән язылганын, Җәлил үзе исән чагында – суд процессы башлануга ярты ай элек – камерадашы бельгияле Андре Тиммерманска тапшыра. Тиммерманс язмаларны әнисенә — Бельгиягә озата. Исән-сау өенә кайтырга насыйп булган дусты әлеге дәфтәрләрне 1947 елда Брюссельдәге илчелек аша СССР Язучылар союзына җибәрә. Бу дәфтәрләргә шагыйрьнең төрле шартларда язылган шигырьләре туплана. Беренче дәфтәрендә 62 шигырь, ә икенчесендә 50 шигырь тупланган. Әмма аларның 19 ике дәфтәрдә дә кабатлана. Димәк, 93 шигырь. М.Җәлилнең өченче дәфтәре булганлыгы турында да сүзләре йөри. Әмма ул әле табылмаган).

*12. М.Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме кайчан бирелә?* (1956 елда).

*13. «Моабит дәфтәрләре» нинди телләргә тәрҗемә ителгән дип уйлыйсыз?* («Моабит дәфтәрләре» рус, француз, испан, алман, гарәп, төрек, кытай, япон, мадьяр, румын, чех һәм башка чит ил халыклары теленә тәрҗемә ителгән).

*14. Казанда Татар дәүләт опера һәм балет академия театры кайчаннан башлап Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры исемен йөртә башлый?* (1957 елдан).

Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА